Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«30» ноябрь 2021 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлыгы булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән 1000,00 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Карап тоту коеларын һәм янгын гидрантларын төзекләндерүне дә кертеп Түбән Чаллы торак пунктының суүткәргеч челтәрләрен алыштыру;
- Түбән Чаллы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров